ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
СПАССКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
СПАС
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ**

**№ 353**

**КАРАР**

**«17» 06 2022 ел**

2022 елның 2 кварталына гражданнарны аз керемлеләр дип тану турында карар кабул итү өчен гражданнар керемен һәм мөлкәт хакының чик күрсәткечләрен раслау турында

Торак кодексының 49,51 статьясы, «Татарстан Республикасы Дәүләт торак фондыннан һәм муниципаль торак фондыннан социаль наем шартнамәләре буенча гражданнарның аларга торак урыннары бирү хокукларын гамәлгә ашыру турында» 2007 елның 13 июлендәге 31-ЗРТ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә, гаиләнең һәр әгъзасына яки ялгыз яшәүче гражданга туры килә торган керемнең һәм гаилә әгъзалары яисә ялгыз яшәүче гражданнан милкендә булган һәм салым салынырга тиешле мөлкәт хакының иң чик күләмнәрен билгеләү методикасы, югарыда аталган законга кушымтада бәян ителгәннәрдән чыгып, Спас муниципаль районының 2022 елның II кварталына торак урыны гомуми мәйданының бер квадрат метрының уртача базар бәясе күрсәткечләре һәм Татарстан Республикасы Спас муниципаль районы Башкарма комитетының 2021 елның 1 октябрендәге 630 номерлы карары нигезендә, Спас муниципаль районы башкарма комитеты
КАРАР БИРӘ:

1. 2022 елның II кварталына гражданнарны аз керемле дип тану турында карар кабул итү өчен чик күрсәткечләрне расларга:
1.1. гаилә әгъзалары (ялгыз яшәүче граждан) милкендәге һәм торак урынны социаль наем буенча торак урын бирү нормасы буенча гаиләнең һәр әгъзасына 386734,50 сум күләмендә торак урынның базар бәясенең тигез исәп-хисап күрсәткеченә тигез салым салынырга тиешле мөлкәт хакы бусагасы.
1.2. һәр гаилә әгъзасына яисә ялгыз яшәүче гражданга туры килә торган керем күрсәткече бусагасы 7519,83 сум күләмендә.

2. Спас муниципаль районы Башкарма комитетының төзелеш һәм торак-коммуналь хуҗалык бүлегенә, Спас муниципаль районы Болгар шәһәр башкарма комитетына торак урыннарына мохтаҗлар буларак исәпкә куелганда әлеге карарның 1.1 һәм 1.2 пунктчаларында күрсәтелгән чик күрсәткечләрдән файдаланырга.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Спас муниципаль районының рәсми сайтында, хокукый мәгълүматның рәсми сайтында урнаштырырга (//http:pravo.tatarstan.ru).

4. Карарның үтәлешен тикшереп торуны үз өстемдә калдырам.

Спас муниципаль районы
Башкарма комитеты җитәкчесе — В.А. Осокин